КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 май г.Казань № 447

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләрен үзгәртеп оештыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Гражданнар оборонасы өлкәсендә дәүләт идарәсе системасын оптимальләштерү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, шулай ук дәүләт мөлкәтен нәтиҗәле файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 1 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен, «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 2 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен, «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 4 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен, «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 5 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте отрядлары) һәм «Татарстан Республикасы Янгыннан саклау хезмәте» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Учреждение), Учреждение эшчәнлегенең төп юнәлешләрен һәм максатын саклап, Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте отрядларын Учреждениегә кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Учреждение, аның штат саны сакланып, тапшыру актлары нигезендә үзенә кушыла торган Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте отрядларының хокуклы варисы булып тора;

үзгәртеп оештыру барышы тулысынча тәмамланганнан соң, Учреждениенең исеме – «Татарстан Республикасы Янгыннан саклау хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе;

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

2022 елның 1 октябренә кадәр «Юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләрен үзгәртеп оештыруга бәйле чараларны үткәрергә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләрен үзгәртеп оештыру чараларын 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрне карап тотуга каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 1 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен төзү турында» 2016 ел, 10 сентябрь, 629 нчы;

«Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 2 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен төзү турында» 2016 ел, 10 сентябрь, 630 нчы;

«Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 4 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен төзү турында» 2016 ел, 10 сентябрь, 631 нче;

«Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең 5 нче отряды (шартнамәле)» дәүләт казна учреждениесен төзү турында» 2016 ел, 10 сентябрь, 632 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин